ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Физик культура һәм спорт турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 18 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 34 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $9^6$ пункт өстәргә:

«$9^6$) Татарстан Республикасы милкендәге спорт объектларын төзүне, реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны, башка спорт корылмаларын булдыруны һәм аларны карап тотуны оештыру;»;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) федераль милектәге, муниципаль милектәге, шулай ук юридик затлар милкендәге, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, яисә физик затлар милкендәге спорт объектларын төзүне, реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны, башка спорт корылмаларын булдыруны һәм карап тотуны оештыруда катнашырга.»;

в) 4 өлештә «спорт объектларыннан» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

2) 11 статьяның 4 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) спорт объектларын төзү, реконструкцияләү һәм аларга ремонт ясау, башка спорт корылмаларын булдыру һәм карап тоту;»;

3) 12 статьяда:

а) 1 өлештә «спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә, «спорт объектларыннан» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

б) $1^2$ өлештә «спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә, «спорт объектларыннан» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

4) 20 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «спорт объектларын» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларын» сүзләрен өстәргә;

5) 27 статьяда:

а) исеменә «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «Спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Халыкның спорт объектлары белән тәэмин ителүгә ихтыяҗы шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә билгеләнә.»;

г) 4 өлештә «шәһәр төзелеше регламентлары» сүзләрен «шәһәр төзелешен зоналаштыру документлары» сүзләренә алмаштырырга;

д) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Спорт объектларын архитектура-төзелеш ягыннан проектлау, төзү һәм реконструкцияләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә, шул исәптән инвалидларның спорт объектларына тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итү турындагы таләпләрне үтәп, гамәлгә ашырыла.»;

е) 6 өлештә «спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә, «спорт объектларында» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларында» сүзләрен өстәргә;

ж) $6^1$ өлештә «спорт объектларының» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларының» сүзләрен өстәргә, «спорт объектларыннан» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

з) түбәндәге эчтәлекле $8^1$ өлеш өстәргә:

«$8^1$. Күчемсез мөлкәт объекты булмаган спорт корылмасыннан Төбәкара, бөтенроссия һәм халыкара физкультура чараларының һәм спорт чараларының бердәм календарь планына, Татарстан Республикасының рәсми физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планнарына кертелгән физкультура чарасын яисә спорт чарасын уздыру өчен файдалану физик культура һәм спорт өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы карары белән Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

и) 10 өлештә «спорт объектлары» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмалары» сүзләрен өстәргә, «спорт объектларыннан» сүзләреннән соң «һәм башка спорт корылмаларыннан» сүзләрен өстәргә;

6) 28 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) физик культура һәм спорт өлкәсендә республика программаларын һәм проектларын, муниципальара программаларны һәм проектларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, шул исәптән Татарстан Республикасы милкендәге спорт объектларын төзүне, реконструкцияләүне һәм аларга ремонт ясауны, башка спорт корылмаларын булдыруны һәм карап тотуны оештыру;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 25 апрель
№ 29-ТРЗ